**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘТКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

**КАРАР**
**унбишенче утырыш**

**13 ноябрь 2021 ел** **№ 59** **Шәтке авылы**

**Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлеге Советының 2018 елның 19 сентябре 87 нче номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында" карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" гы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы авыл җирлеге Советы **карар итте**:

1. Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлеге Советының 2018 елның 19 сентябре 87 нче номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә:

1) 12 статьяның 3 абзацын "12 статьяның 1 өлешендә билгеләнгән очраклардан тыш" сүзләре белән тулыландырырга;

2) 12 статьяны түбәндәге эчтәлекле 1 өлеш белән тулыландырырга:

"1. Җирлекнең генераль планына, шәһәр округының Генераль планына үзгәрешләр әзерләнгән очракта, территорияне комплекслы үстерү турында Карар кабул ителү белән бәйле җәмәгатьчелек фикер алышулары яки гавами тыңлаулар, аңа карата территорияне комплекслы үстерү турында Карар кабул ителгән территория чикләрендә үткәрелергә мөмкин".

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Шәтке авыл җирлеге башлыгы Ф.Г.Кадыйров

СОВЕТ ШАДКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1619000640